**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.07.2015 № 454

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 15 июлендә теркәлде, № 2797

Татарстан Республикасының
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгындагы
дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының,
аларны биләгәндә, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә
чит илләрнең Россия Федерациясе территориясеннән
читтә урнашкан банкларында счетлар (кертемнәр)
ачу һәм шуларга ия булу, кулларындагы (наличный)
акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау,
чит илләрнең финанс коралларына ия булу
һәм (яки) алардан файдалану
тыела торган исемлеген раслау хакында

“Затларның аерым категорияләренә чит илләрнең Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм шуларга ия булуны, кулларындагы (наличный) акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны, чит илләрнең финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы № 79-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты “и” пунктчасына һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының, аларны биләгәндә, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә чит илләрнең Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм шуларга ия булу, кулларындагы (наличный) акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган исемлеген раслау хакында” 2015 елның 8 июнендәге № ПУ-542 Указының 2 пунктына туры китереп, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының, аларны биләгәндә, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә чит

илләрнең Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм шуларга ия булу, кулларындагы (наличный) акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган исемлеген (кушымта итеп бирелә) (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар бүлегенә:

а) Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлектә күрсәтелгән вазыйфаларын биләүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга;

б) бу боерык белән расланган Исемлекне өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләткә хезмәт итү һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә тапшырырга.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2015 елның 6 июлендәге № 454 боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының, аларны биләгәндә, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә чит илләрнең Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм шуларга ия булу, кулларындагы (наличный) акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган исемлеге

1. Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәтенең Татарстан Республикасының Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары реестры турында” 2006 елның 18 гыйнварындагы № ПУ-9 Указы белән расланган реестры тарафыннан югары вазыйфалар төркеменә кертелгән вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары.